СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

30.11.2022 | с. Введенская Слобода | №22-223

«Учак ягу урыннарын һәм ысулларын билгеләү, чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм әйберләрне яндыру турында» Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының 2017 елның 24 октябрендәге 39-175 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 октябрендәге 1885 номерлы карары белән

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Учак ягу урыннарын һәм ысулларын билгеләү, чүп-чарны, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм әйберләрне яндыру турында» Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының 2017 елның 24 октябрендәге 39-175 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Торак пунктларның гомуми кулланылыштагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан хосусый йорт биләмәләрендә азык әзерләү өчен махсус бүлеп бирелгән һәм җиһазландырылган урыннардан читтә ачык ут куллану, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яисә эшләнмәләр яндыру тыела».

2. Әлеге карар җирлек территориясендә махсус янгынга каршы режим кертү чорында үз көченә керми.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Введенский Бистәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
ТР, Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов